**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ НОВОИЛЬМОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица Ключевая, дом 19, село Новое Ильмово, Черемшанский район, РТ, 423118

**ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ЯҢА ЭЛМӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Чишмә урамы, 19 нче йорт, Яңа Элмәле авылы, Чирмешән районы, РТ, 423118

Телефон: (84396) 2-45-51, факс: (84396) 2-45-51 email: Nilm.Cmn2@tatar.ru

**№ 28** **04.05.2026 ел**

**Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының «Авыл җирлегенең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 30 декабрендәге 23 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 19.01.2026 № 7 карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының «Авыл җирлегенең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 30 декабрендәге 23 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «2.2. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатында түбәндәге функцияләрне башкара:

- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү, шулай ук гадәттән тыш хәлләр яки янгын нәтиҗәсендә зыян күргән яки җимерелгән торак йортларны, торак-коммуналь хуҗалык объектларын, социаль өлкәне, җитештерү һәм инженерлык инфраструктурасын торгызу һәм төзү өлкәләрендәге мәсьәләләрне үз компетенциясе чикләрендә карый һәм билгеләнгән тәртиптә үз тәкъдимнәрен кертә;
- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә, шулай ук авыл җирлеге территориясендә гражданнар оборонасы өлкәсендә норматив хокукый актларны һәм норматив документларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшли;

- авыл җирлеге территориясендә гадәттән тыш хәлләр һәм янгыннар килеп чыгу мөмкинлеген карый, гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә, бетерүгә һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә, шулай ук гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар эшләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыра;

- гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясенең дәүләт программаларын эшләүдә катнаша һәм аларны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр әзерли;

- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең Россия бердәм системасы объект звеноларының нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү һәм үстерү, шулай ук гражданнар оборонасы эшчәнлеге буенча тәкъдимнәр эшли;

- гражданнар оборонасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшли;

- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, алардан килгән зыяннарны бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча, шулай ук гражданнар оборонасы өлкәсендә чараларны планлаштыруны оештыра, аларның үтәлешен тикшереп тора;

- федераль һәм төбәкара характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү, күрсәтелгән гадәттән тыш хәлләр, мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә зыян күргән һәм җимерелгән торак йортларны, торак-коммуналь хуҗалык объектларын, социаль өлкәне, җитештерү һәм инженерлык инфраструктурасын торгызу һәм төзү, шулай ук гуманитар чаралар күрү операцияләрен уздыру буенча тәкъдимнәр эшли;

- авыл җирлеге башлыгы өчен халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр, аналитик һәм статистик материаллар әзерләү эшен оештыра;

- вакытлыча күчерелә торган (эвакуацияләнә торган) халыкны урнаштыруны оештыру һәм гадәттән тыш хәлләр һәм янгыннар бетерелгәннән соң аны яшәү урыннарына кайтару мәсьәләләрен карый;

- авыл җирлеге территориясендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның һәм гражданнар оборонасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссияләре белән үзара хезмәттәшлекне оештыра.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Яңа Элмәле авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе И.М.Җамалтдинов